ГЛАВА
БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ОЛЫ ЕЛГА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

422640, Олы Елга,
Октябрь урамы, 25 йорт

Тел.: (84361) 25-264, факс: (84361) 25-265, эл.адрес: Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02 ноябрь 2022 ел Олы Елга ав. № 4

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Елга авыл
жирлегенең Саескан Тавы
авылы торак пунктында
гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча гражданнар
жыенын билгеләү турында

"Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, "Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл жирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл жирлегенең Саескан Тавы авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын 2022 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл жирлегенең Олы Елга авылы территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме һәм көндезге бүлектә торып укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару :

– Олы Елга авылы суүткәргеч магистраленең су задвижкаларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– авыл җирлеге торак пунктларындагы урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

– Олы Елга авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап тотуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);

– Саескан Тавы авылында контейнер мәйданчыгы ясау һәм төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

– Олы Елга авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу, урнаштыру, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);

- суэтем башнясын сатып алу, монтажлау һәм урнаштыру (килешү буенча эшләрне түләү);
- мотопомпа өчен янгын җиңнәре сатып алу.

"ЯКЛАП" "КАРШЫ".

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карар игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы И.Н.Мингалеев